ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының $35^{8.2}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының $35^{8.2}$ статьясына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче өлештә:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан су чыгару скважиналарының географик координаталары күрсәтелгән ситуация планы (өч нөсхәдә);»;

б) алтынчы абзацта «һәм нигезләү» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) икенче өлешнең өченче, дүртенче һәм җиденче абзацларын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 17 июль
№ 58-ТРЗ